| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**05 июль 2023 ел** Хуҗа Хәсән ав. № 27

Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитетының ««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2019 елның 18 февралендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитетының ««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2019 елның 18февралендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында»;

1 пунктның 1.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырыла торган җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге».

1.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайты турында нигезләмәдә:

2.2. пунктының 2.2.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә ачыклыкны һәм муниципаль мәгълүмат ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Функцияләр

3.1. Сайтның төп функцияләре:

3.1.1. «Интернет» халыкара компьютер мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Хуҗа Хәсән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының (алга таба - авыл җирлеге җирле үзидарә органнары) даими мәгълүмати эшчәнлеген тәэмин итү;

3.1.2. Җирле халыкта һәм башка районнар, шәһәрләр һәм регионнар халкында авыл җирлеге һәм район тормышына тотрыклы кызыксыну формалаштыру;

3.1.3. Авыл җирлеге һәм район, башка районнар, шәһәрләр, регионнарда яшәүчеләрнең мәгълүмати ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

3.1.4. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында гражданнарга, шәхси эшмәкәрләргә һәм юридик затларга мәгълүмат бирү;

3.1.5. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек белән дөрес мәгълүматтан, шул исәптән яңалык мәгълүматыннан вакытында файдалана алу юлы белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;

3.1.6. Авыл җирлегенең җирле үзидарә бүлеге эше турында белешмә мәгълүмат бирү;

3.1.7. Авыл җирлегенең тормышы турында белешмә мәгълүмат бирү;

3.1.8 Халыктан кире элемтә алу.»;

5 бүлекнең 5.2. пунктын төшереп калдырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында мәгълүмат бастырып чыгару тәртибендә:

2 бүлекнең 2.1 пунктында «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң
« Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге» сүзләрен өстәргә;

2 бүлекнең 2.2. пунктын төшереп калдырырга;

3.1 статьяның 3 пунктындагы 2 абзацында «муниципаль берәмлек» сүзләрен «Хуҗа Хәсән авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырыла торган Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлегендә:

1 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1. | Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба җирле үзидарә органнары) турында гомуми мәгълүмат, шул исәптән:» | | |

2.2. юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.2. | Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советына кертелгән муниципаль хокукый актлар проектлары текстлары | муниципаль хокукый актлар проектлары кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетына» | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе С.П.Матвеева

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Хозесановского сельского поселения